| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН ГЛАВА ЕЛАУРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЕЛАУР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ** |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ Елаур ав. КАРАР

«14» октябрь 2022 ел № 5

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Елаур авыл җирлегендә Елаур авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, муниципаль районның Елаур җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районы Елаур авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2022 елның 28 октябрендә 10 сәгать 00 минутка Елаур авылы, Үзәк урамы 25 йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йортында Үзәк урам буенча 1-85нче, Яшьләр урамы буенча 3-25нче, Пионер урамы буенча 2-5нче, Комсомол урамы буенча 5-23нче, Чапаев урамы буенча 1-22 нче йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2022 елның 28 октябрендә 13 сәгать 00 минутка Елаур авылы, Центральная урамы 25 йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йортында Ленин урамы буенча 1-69нчы, Калинин урамы буенча 1-68нче, Елга арьягы урамы буенча 4-14нче, Җиңүнең 40 еллыгы урамы буенча 2-10 нчы йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. Елаур авылында яшәүчеләр җыенын уздыру өчен исемлекне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

4. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Елаур авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Елаур авыл җирлегенең Елаур авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидтан тыш, 2023 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

Елаур торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге авыл эчендәге юлларны ремонтлау (юл полотносын күтәрү, ташны сатып алу, ташу, вак таш җәю, транспорт хезмәтләре);

авыл эчендәге юлларны сезонлы карап тоту;

« РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) http://pravo.tatarstan.ru Нурлат муниципаль районы рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Елаур торак пунктындагы мәгълүмат стендларында, гражданнар җыены этапларын үткәрү көненә 10 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Елаур авыл җирлеге башлыгы О.В.Охотникова